# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Айбаш авыл җирлеге Зур Көек торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

11 ноябрь 2022 ел № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Зур Көек авылы территориясендә гражданнарның 2021 елда җыелган үзара салым акчаларының калган өлешен түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга ризамы?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (ТР Биектау районының Зур Көек торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен су алу җайланмасы булдыру мөмкинлеге турында килешү буенча түләү, шулай ук скважина бораулау проектын эшләүгә түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 63 (алтмыш өч) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 35 кеше, бу 55,5% ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 35 (утыз биш) катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Зур Көек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге Зур Көек авылы территориясендә гражданнарның 2021 елда җыелган үзара салым акчаларының калган өлешен түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (ТР Биектау районының Зур Көек торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен су алу җайланмасы булдыру мөмкинлеге турында килешү буенча түләү, шулай ук скважина бораулау проектын эшләүгә түләү)

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р. Сафиуллин